# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«11» 03 2025 ел Яр Чаллы № 694

«Кибердружина төзү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 октябрендәге 3991 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2024 елның 30 ноябрендәге 438-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә Башкарма комитет

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Кибердружина төзү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 октябрендәге 3991 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 кушымтаның 3 пунктын «а» пунктчасы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балаларда наркотик чаралар, психотроп һәм (яки) аңын томалый торган матдәләр, тәмәке әйберләре, алкоголь һәм спиртлы продукция куллану, комарлы уеннарда катнашу, сукбайлык яки теләнчелек белән шөгыльләнү теләге уятырга сәләтле;» (үз көченә керү датасы 01.03.2025).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю.П. Васильевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев